ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

БОЕРЫК — БОЕРЫК

17.10.2019 — Казан ш. — № 112

Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең норматив хокукый актларын федераль законнарга яраштыру максатларында

Боерык бирәм:

1. Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче башлык урынбасарларына, структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренә әлеге Регламент нигезләмәләренә тайпылмыйча таянып эш итәргә.

3. Хокук идарәсенең юридик бүлегенә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына җибәрергә.

4. Җыелма анализ бүлегенә Регламентны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең (алга таба – Инспекция) рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Инспекциянең түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2019 елның 5 февралендәге 12 номерлы;

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 5 февралендәге 12 номерлы боерыгы белән расланган Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 29 апрелендәге 55 номерлы;

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 5 февралендәге 12 номерлы боерыгы белән расланган Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 13 июнендәге 71 номерлы.

6. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның «_17__» октябрендәге № 112___ боерыгы белән расланды

**Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар булып түбәндәгеләр тора:

а) өлешле төзелеш объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленә кадәр алынган очракта:

төзүче оешмалар – хуҗалык җәмгыятьләре:

мөлкәтендә яисә арендалау хокукында, субарендалау хокукында яки «Төзелешне үстерүгә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{10}$ статьясының 2 пунктындагы 5 пунктчасында каралганча түләүсез нигездә файдалану хокукында җир кишәрлеге булган һәм «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге җир кишәрлегендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә), производство билгеләнешендәге объектлардан тыш, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен төзелешкә алынган рөхсәт нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүчеләр;

б) өлешле төзелеш объектын төзүгә рөхсәт 2018 елның 1 июленнән соң алынган очракта:

төзүче оешмалар – хуҗалык җәмгыятьләре:

мөлкәтендә яисә арендалау хокукында, субарендалау хокукында яки «Төзелешне үстерүгә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{10}$ статьясының 2 пунктындагы 5 пунктчасында каралганча түләүсез нигездә файдалану хокукында җир кишәрлеге булган һәм «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә әлеге җир кишәрлегендә күпфатирлы йортларны һәм (яисә), производство билгеләнешендәге объектлардан тыш, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен төзелешкә алынган рөхсәт нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүчеләр;

аталышларында «махсуслаштырылган төзүче» сүзләре булган.

1.2.1. Проект декларациясе, Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның $3^2$ статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән физик затның туры килүе турында мәгълүмат төзүче оешма тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, проект декларациясенең электрон формасын тутыру юлы белән, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында үзенең шәхси кабинеты аша җибәрелә.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең (алга таба – Инспекция) өлешле төзелешне тикшереп тору бүлеге тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Инспекция урнашкан урын: Казан шәһәре, Зур Кызыл ур., 15/9.

Инспекциянең өлешле төзелешне тикшереп тору бүлегенең урнашу урыны (алга таба – Бүлек): Казан шәһәре, Декабристлар ур., 81.

Инспекциянең һәм бүлекнең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.30 сәгатьтән алып 17.30 сәгатькә кадәр, җомга 8.30 сәгатьтән алып 16.30 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, Инспекциянең эш көннәрендә.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

Инспекциянең белешмә телефоннары: 237-91-87, 518-36-92.

1.3.2. Инспекциянең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://gsn.tatarstan.ru.

Инспекциянең электрон почта адресы: gsn@tatar.ru.

1.3.3. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Инспекция урнашкан урын һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Инспекция холлында урнашкан, дәүләт хезмәте турында Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә визуаль һәм тестлы мәгълүматларны үз эченә алган, дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Инспекциянең рәсми сайтында (http://gsn.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Инспекциягә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

4) Инспекциягә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша).

1.3.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре буенча барлык кирәкле мәгълүмат Бүлектә төзелә һәм Инспекция бүлмәләрендә Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла, шулай ук Инспекциянең рәсми сайтында урнаштыру өчен җыелма анализ бүлегенә тапшырыла.

Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3-2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы (алга таба – РФ ШрК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, 16 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Җир кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, № 44, 4147 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ ТК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 1, 14 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, №1, 40 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Торак төзелешен үстерүгә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 161-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 30, 3617 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010

елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Төзүче оешмалар бөлгенлеккә төшкәндә (банкрот булганда) гражданнар – өлешле төзелештә катнашучылар хокукларын яклау буенча гавами-хокук компаниясе турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017 елның 31 июле, № 31 (1 өлеш), 4767 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йортлар төзү (булдыру) өчен гражданнарның һәм юридик затларның акчаларын җәлеп итү хокукына ия булган төзүче оешманың үз акчаларын исәпләү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 11 июнендәге 673 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – 2018 елның 11 июнендәге 673 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 25, 3693 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы сайты адресын билгеләү турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 1133 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 40, 6137 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзүче оешма эшчәнлегенең финанс тотрыклылыгын бәяләү нормативлары турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1683 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 18, 2001 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы турында» 2019 елның 26 мартындагы 319 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 38, 4823 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Проект декларациясе рәвешен раслау турында» 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгы (алга таба – 996/пр номерлы Россия Төзелеш министрлыгы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы, http://pravo.gov.ru, 2016, 30 декабрь, басылып чыгу номеры: 0001201612300099, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның

30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1[1] һәм 2 өлешләрендә, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве турында бәяләмә формасын раслау турында» 2018 елның 11 октябрендәге 653/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш Министрлыгының 653/пр номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 28 декабрь, басылып чыгу номеры: 0001201812280059);

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортлар төзүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 66-ТРЗ номерлы ТР Законы) (Республика Татарстан, 2007, 28 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карары (алга таба – 622 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 43, 1707 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзелешенә төзелеш өчен гражданнардан акча җәлеп итүче затлардан, торак-төзелеш кооперативыннан һәм мондый кооператив күпфатирлы йорт төзелешенә бәйле шартнамәләрне төзегән бүтән затлардан алына торган гражданнарның акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләр, мәгълүматлар һәм (яки) документлар исемлекләре турында» 2013 елның 11 октябрендәге 750 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, №77, 2609 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.5. Әлеге регламентта кулланыла торган терминнар һәм аларның

билгеләмәләре:

**вәкаләтле банк** – Россия Федерациясе законнары нигезендә булдырылган һәм Россия Банкы тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән критерияләргә туры килүче банклар исемлегенә кертелгән банк. Россия Банкы ай саен аталган исемлекне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үзенең рәсми сайтында урнаштыра;

**мөрәҗәгать итүчеләр** – әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән билгеләмәләр нигезендәге төзүче оешмалар (аларның вәкаләтле вәкилләре);

**Бүлек** – өлешле төзелешне тикшереп тору бүлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эш башкаручы;

**дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк** (күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

**дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны** – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль районы (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

**техник хата** – Инспекция тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта **дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза** (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында таләп булуы аңлашыла (Инспекциянең шәхси кабинетына көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында проект декларациясенең электрон формасын тутыру юлы белән торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы аша җибәрелгән проект декларациясе) (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт |
| --- | --- | --- |
| 1 | 2 | 3 |
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 6 өлешенең 12 пункты<br>214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы $2^{1-1}$, $2^2$ өлешләре |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе | 622 номерлы ТР МК карары;<br>214-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә) (1 нче кушымта), яисә төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 6 өлешенең $1^2$ пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирүдән нигезле баш тарту (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту) (2 нче кушымта). | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | Төзүче оешма тарафыннан, проект декларациясенең электрон формасын тутыру юлы белән, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында үзенең шәхси кабинеты аша көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны кулланып, проект декларациясен, физик затның 214-ФЗ номерлы Федераль законның $3^2$ статьясының 4 өлешендә билгеләнгән физик затка туры килүе турында мәгълүматны җибәрү датасыннан соң егерме эш көненнән артмаган срокта.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ, көчәйтелгән квалификацияле имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасыннан файдаланып бирелә. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы $2^1$ өлешләре |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм | Проект декларациясе, Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның $3^2$ статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 2 өлеше |

| | | |
|---|---|---|
| мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | физик затның туры килүе турында мәгълүмат төзүче оешма тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, проект декларациясенең электрон формасын тутыру юлы белән, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында үзенең шәхси кабинеты аша җибәрелә.<br>Мөрәҗәгать итүче Инспекциягә кәгазьдә өстәмә рәвештә тапшырырга хокуклы булган документлар:<br>күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын (алга таба – Объект) төзү (булдыру) өчен гражданнарның һәм юридик затларның акчасын җәлеп итүче юридик зат җитәкчесе вазыйфасына сайлау турында яисә билгеләү турында, ышанычнамәдән башка күрсәтелгән юридик зат исеменнән аңа эш йөртү хокукын бирә торган карар;<br>төзүче оешманың үзкөйләнешле һәм башка оешмаларда әгъзалыгы турында таныклык (әгәр мондый оешмаларның әгъзасы булып торса);<br>Россия Федерациясе Төзелеш министрлыгының 2016 елның 20 декабрендәге 996/пр номерлы боерыгына кушымтаның 55 пунктында күрсәтелгән инженерлык-техник тәэминат челтәренә тоташуга техник шартлар һәм инженер-техник тәэминат шартнамәсе;<br>төзелеш проектын гамәлгә ашыру графигы, аны гамәлгә ашыру этаплары һәм вакыты, шул исәптән төзелеп килүче (төзелә торган) күпфатирлы йортларны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын файдалануга тапшыруга рөхсәт алу срогы турында мәгълүматны үз эченә ала;<br>Объект төзелеше проектын техник-икътисадый нигезләү, шул | |

| | | |
|---|---|---|
| | исәптән Объектның бәясен күрсәтеп, җыелма-сметалы исәп-хисап;<br>кертелгән барлык үзгәрешләрен үз эченә алган проект документлары, өстәмә программалар урнаштыруны таләп итми торган DVD-R форматындагы электрон форматта;<br>Объект проектын эшләгән оешмадан, торак биналарның төп характеристикаларын, гомуми кулланылыштагы урыннарны, торак булмаган биналарны күрсәтеп, белешмә;<br>Объект проектын эшләгән оешмадан, Объектның технологик һәм инженерлык җиһазларының исемлеген һәм характеристикаларын күрсәтеп, белешмә;<br>Объект проектын эшләгән оешмадан территорияне төзекләндерүнең планлаштырылган элементлары турында белешмә;<br>бухгалтерия хисаплылыгының төгәл булуын раслаучы аудитор бәяләмәсе (төзүче оешма тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеге гамәлгә ашырылган хисап чорлары өчен);<br>өлешле төзелеш Объектын һәм/яисә Объект төзелеше өчен бүленгән җир кишәрлеген залогка тапшырып җәлеп ителгән кредит (заем) акчаларының күләмен күрсәтеп;<br>Дәүләти экология экспертиза нәтиҗәләре (Федераль закон нигезендә мондый экспертиза үткәрү кирәк булганда);<br>төзүче оешманың бер кулдагы башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашыручы затның, төзүче оешманың баш бухгалтерының яисә бухгалтерлык исәбенә алып бару йөкләнгән башка вазыйфаи затының яки төзүче оешманың бухгалтерлык исәбен алып бару буенча хезмәтләр күрсәтү турында шартнамә төзелгән | |

| | | |
|---|---|---|
| | затның шәхес таныклыклары күчермәләре;<br>җир кишәрлегенең шәһәр төзү планы;<br>инженерлык эзләнү нәтиҗәләре;<br>проект документациясенә дәүләт экспертизасы бәяләмәсе.<br>төзелешкә рөхсәт;<br>Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт.<br>Әгәр әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль тапшырылмаган булса, алар тиешле органнарда бүлек белгечләре тарафыннан соратып алына. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт | Юридик зат-төзүчегә карата гомуми файдаланудагы сайтлардан файдаланып, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кысаларында алынырга мөмкин булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшыру хокукына ия булган документлар:<br>юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Россия ФСХ) өземтә (белешмәләр);<br>мөрәҗәгать итүченең салымнарны, җыемнарны һәм башка төрле зарури түләүләрне түләүдә бурычлары булмавы турында мәгълүматлар (белешмә) (Россия ФСХ);<br>барлык дәрәҗә бюджетларына узган/агымдагы финанс елында юридик зат тарафыннан фактта түләнгән салымнарның суммасы турында белешмәләр (Россия ФСХ);<br>күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан аерым затта күчемсез мөлкәт объектына карата булган хокуклар турында өземтә (белешмәләр) (Россия ФСХ);<br>күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче тарафыннан объект төзү (булдыру) эше гамәлгә ашырыла | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлеше, 20 һәм 21 статьялары, |

| | | |
|---|---|---|
| органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | торган җир кишәрлегенә карата өземтә (белешмәләр) (Россия ФСХ);<br>төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы вазыйфаларын гамәлгә ашыручы затларның, төзүче оешманың баш бухгалтерының, корпоратив юридик затка – төзүче оешмага ахыр чиктә турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аркылы) ия булган (капиталында биш проценттан артык өлешендә катнашучы) физик затның ябылмаган хөкеме турында мәгълүматлар (Россия ЭЭМ);<br>төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы вазыйфаларын гамәлгә ашыручы затларның, төзүче оешманың баш бухгалтерының, корпоратив юридик затка – төзүче оешмага ахыр чиктә турыдан-туры яки читләтеп (өченче затлар аркылы) ия булган (капиталында биш проценттан артык өлешендә катнашучы) физик затның квалификациясен алу рәвешендә административ җәзасы булуы турында мәгълүматлар (Россия ФСХ).<br>Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Мөрәҗәгать итүчедән югарыда саналган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган документларны, шулай ук кабул итүдән яисә дәүләт хезмәтен яки муниципаль хезмәтне күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәтен яки муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документларны таләп итү тыела, 210-ФЗ номерлы Федераль | |

| | | |
|---|---|---|
| | законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында «а»-»г» пунктчаларында санап үтелгән очраклардан тыш | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр юк | 214-ФЗ номерлы Федераль закон |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктату яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары территориясендә төзелеше башкарыла торган, аларга карата 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының көче туктатылмаган объектка карата дәүләт хезмәте күрсәтү буенча мөрәҗәгать итү;<br>төзүче оешманың 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $^{1}1$ һәм 2 өлешендә, $3^2$ статьясында каралган таләпләргә җавап бирмәү фактлары ачыклану;<br>төзүче оешманың проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәү фактлары ачыклану;<br>документларда күрсәтелгәннәргә туры килми торган мәгълүматларны ачыклау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү вакытына үз көчен югалткан яисә гамәлдә булу вакыты чыккан документларны тапшыру (документның гамәлдә булу вакыты документның үзендә күрсәтелгән булса яисә законнарда билгеләнгән булса, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган башка очракларда);<br>мөрәҗәгать итүченең һәм документларның закон таләпләренә | 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының $2^2$ өлеше, 66-ТРЗ номерлы ТР Законы |

| | | |
|---|---|---|
| | җавап бирү фактын раслый торган, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратып алынган документларның һәм белешмәләрнең булмавы.<br>Мөрәҗәгать итүчегә шушы пунктның икенче абзацында каралган нигезләрдә ярашлылык турында бәяләмә бирелгән очракта яисә мөрәҗәгать итүчегә мондый бәяләмә бирелгән датадан соң алтмыш көн эчендә аның тарафыннан күпфатирлы йортны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын өлешле төзүдә катнашучының беренчесе белән шартнамәне дәүләт теркәвенә алу буенча документлар тапшырылмаган булса, проект документациясе шушы Регламентта билгеләнгән тәртиптә Инспекциягә яңадан җибәрелергә тиеш<br>Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләрен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Мөрәҗәгать итүче тарафыннан торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында проект декларациясенең электрон формасы тутырылуга бәйле рәвештә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсенең дә мөрәҗәгать итүчегә шулай ук торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы аша җибәрелүе сәбәпле, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда чират көтү срогы күздә тотылмый. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гарызнамәченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында Инспекциянең шәхси кабинетына көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, проект декларациясенең электрон формасын тутыру юлы белән җибәрелгән проект декларациясен, 214-ФЗ номерлы Федераль законның $3^2$ статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән физик затның туры килүе турындагы мәгълүматны теркәү, әгәр гариза 16.00 сәгатькә кадәр килгән булса, эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла, әгәр гариза 16.00 сәгатьтән соң килгән булса – киләсе эш көнендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, | Дәүләт хезмәтен күрсәтү Казан шәһәре, Декабристлар ур., 81 йорт адресы буенча урнашкан Инспекция бинасы холлында гамәлгә ашырыла, ул түбәндәгеләр белән җиһазланган булырга тиеш: һаваны кондиционерлау системасы белән; янгынга каршы система белән; мәгълүмати стенд, документларны рәсмиләштерү өчен зарури җиһазлар белән.<br>Бинада дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү урынына инвалидлар өчен каршылыксыз үтеп керү тәэмин ителә. Инвалидларга файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өчен бинага керү юлының уң ягында пандус корыла, аның аша мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр бинага үтеп керә | |

| | | |
|---|---|---|
| шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү, тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>2) мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итүче белгечләрнең, шулай ук биналарның тиешле санда булуы;<br>3) дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәренең мәгълүмат ресурсларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә тулы мәгълүмат булу;<br>4) мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен бинага дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга каршылыкларсыз үтеп керүен тәэмин итү (бинага һәм аның чикләрендәге бүлмә урыннарына җайлы керү-чыгу);<br>5) инвалидларга аларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү. | |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтен һәм (яки) муниципаль хезмәтне алу турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган гариза тапшыру (комплекслы гарызнамә) юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен алу (шул исәптән тулы күләмдә) яки ала алмау мөмкинлеге; | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>1) документларны кабул итү һәм карау вакытларын үтәү;<br>2) дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу вакытын саклау;<br>3) документларны кабул иткәндә һәм мөрәҗәгать итүчеләргә тапшырганда чиратлар булмау;<br>4) дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр булмау.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүче белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итүе күздә тотыла.<br>Дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыннарында күрсәтү гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат шәхси мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән телефон буенча) Бүлек башлыгыннан, Инспекциясенең рәсми сайтыннан (http://gsn.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы гарызнамә составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен | Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында консультация Инспекциянең рәсми сайтындагы интернет-кабул итү системасы аша электрон рәвештә алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте электрон формада төзүче оешма тарафыннан | 214-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | проект декларациясен, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның $3^2$ статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән физик затның туры килүе турында мәгълүматны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, проект декларациясенең электрон формасын тутыру юлы белән, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында үзенең шәхси кабинеты аша җибәреп күрсәтелә. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

### 3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә (алга таба – ярашлылык турында бәяләмә) бирү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

ярашлылык турында бәяләмәне яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тартуны әзерләү һәм тапшыру;

техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү.

### 3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультация алу буенча Инспекциягә телдән (шәхсән яисә телефон буенча) яисә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итүе административ процедураны башлау өчен нигез булып тора.

Телдән мөрәҗәгать иткән очракта Бүлек белгече мөрәҗәгать итүне консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча, һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

Әгәр гражданин мөрәҗәгатенә язмача җавап алырга тели икән, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчене язмача консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча.

Мөрәҗәгать итүченең телдән мөрәҗәгатенә мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне җавап бирелә.

Язмача мөрәҗәгатькә җавап – мөрәҗәгатьне теркәүгә алган датадан соң утыз календарь көне эчендә.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация; мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен

кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

### 3.3. Ярашлылык турында бәяләмәне яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тартуны әзерләү һәм тапшыру

3.3.1. Ярашлылык турында бәяләмәне яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тартуны тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә түбәндәге административ гамәлләр башкарыла:

1) Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү;

2) Гаризаны карау;

3) Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара таләпләр формалаштыру (җибәрү) һәм гомуми файдаланудагы сайтлардан мәгълүмат алу;

4) Ярашлылык турында бәяләмә яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тартуны формалаштыру;

3.3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны теркәү.

Төзүче оешма тарафыннан проект декларациясен, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның $3^2$ статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән физик затның туры килүе турында мәгълүматны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, проект декларациясенең электрон формасын тутыру юлы белән, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында үзенең шәхси кабинеты аша җибәрү административ гамәлне башлап җибәрү нигезе булып тора.

3.3.2.1. Бүлек белгечләре проект декларациясенең электрон формасын тутыру юлы белән, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып, торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында Инспекциянең шәхси кабинетына килгән проект декларациясен, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның $3^2$ статьясындагы 4 өлешендә билгеләнгән физик затның туры килүе турында мәгълүматны (алга таба – гариза) кучертеп ала һәм аны теркәү өчен электрон рәвештә Документлар белән тәэмин итү һәм контроль бүлегенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура, гариза 16:00 сәгатькә кадәр килеп ирешкән очракта, эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла, әгәр гариза 16:00 сәгатьтән соң килгән булса – икенче эш көнендә.

3.3.2.2. Документлар белән тәэмин итү һәм контроль бүлеге белгече:

гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында (алга таба – электрон хөкүмәт) терки;

гаризаны Инспекция башлыгына карау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Документлар белән тәэмин итү һәм контроль бүлегенә гариза кергәннән соң бер эш көненнән соңга калмыйча

гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Инспекциягә җибәрелгән, теркәлгән гариза (контрольлек итүче органның шәхси кабинетында); Инспекция башлыгына карап тикшерүгә җибәрелгән, электрон хөкүмәт буенча теркәлгән гариза.

3.3.3. Гаризаны карау.

Инспекция башлыгы гаризаны карый һәм, резолюциясен куеп, аны Инспекция башлыгының беренче урынбасары юллый.

Инспекция башлыгының беренче урынбасары әлеге гаризаны карый һәм резолюциясе белән аны Бүлек башлыгына юллый.

Бүлек башлыгы җаваплы башкаручыны билгели һәм гаризаны үтәү өчен юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән соң килүче эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: әлеге Регламентта билгеләнгән тәртиптә эшләү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру (җибәрү) һәм гомуми файдаланудагы сайтлардан мәгълүмат алу.

3.3.4.1. Бүлек белгече дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнарга, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнарга, дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт органнарының яисә җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуында булган оешмаларга, ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү эшендә катнашучы бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына шушы Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры китереп белешмәләр алу өчен ведомствоара гарызнамәләр җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән гарызнамәләр.

3.3.4.2. Инспекция гарызнамәләре буенча хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнар тарафыннан автоматлаштырылган режимда түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

гарызнамәне эшкәртү һәм сорала торган белешмәләрне эзләү;

ведомствоара электрон хезмәттәшлек итү ярдәмендә сорала торган белешмәләрне формалаштыру, яки, сорала торган белешмәләр булмаган очракта, сәбәпләрен күрсәтеп, соралучы белешмәләрне баш тарту турында беледерүнамә җибәрү.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура законнарда билгеләнгән чорларда гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (белешмәләр) яки белешмәләрне бирүдән баш тарту турында хәбәрләмә.

3.3.4.3. Бүлек белгече гомуми файдаланудагы сайтлардан электрон рәвештә юридик зат-төзүчегә карата түбәндәгечә мәгълүматлар ала:

Россиянең Федераль салым хезмәте сайтыннан egrul.nalog.ru –

ликвидацияләнү процедурасыны булуы (булмавы) турында;

Россия Федерациясе Арбитраж судлары сайтыннан kad.arbitr.ru – банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсенең алып барылуы турында карар булуы (булмавы) турында, административ җәзага тартылу рәвешендә эшчәнлекнең туктатылуы турында;

Сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасы сайтыннан old.zakupki.gov.ru – намуссыз тәэминатчылар реестрында белешмәләр булуы (булмавы) турында, бу реестр «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла;

Россиянең Монополиягә каршы федераль хезмәт сайтыннан rnp.fas.gov.ru – намуссыз тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрында белешмәләр булуы (булмавы) турында, бу реестрны алып бару «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла;

Россия Федерациясенең сатулар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру сайтыннан torgi.gov.ru – җир кишәрлеген сату буенча аукционда яисә җир кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучылар реестрында белешмәләр булуы (булмавы) турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.3 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гомуми файдаланудагы сайтлардан алынган мәгълүматлар.

3.3.5. Ярашлылык турында бәяләмә яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тартуны формалаштыру

3.3.5.1. Шушы Регламентның 3.3.4 пунктында каралган административ гамәлләрнең нәтиҗәләре административ гамәлне башлау өчен нигез булып тора.

Бүлек белгече:

гомуми файдаланудагы сайтлардан, мөрәҗәгать итүчеләрдән һәм, әлеге Регламентның 3.3.4 пунктына туры китереп, ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибендә алынган документларны (мәгълүматларны) карый һәм анализлый;

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү максатыннан, шәхси мәгълүматлар субъектыннан аның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык соратып ала;

өлешле төзелеш өлкәсендә контроль тәэмин итү кысаларында мәгълүматларны тикшерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирлеү зидарә органнарының күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортны төзү өчен гражданнарның төзелеш өчен гражданнар акчаларын җәлеп итүче затлардан, торак-төзелеш кооперативыннан һәм мондый кооператив күпфатирлы йортны төзү белән бәйле шартнамәләр төзегән бүтән затлардан алына торганакчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлегенә дәүләт

тикшерүен (күзәтчелегеН) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен башкаруы өчен кирәк булган белешмәләр, мәгълүматлар һәм (яки) документлар исемлекләре турында» 2013 елның 11 октябрендәге 750 номерлы карарына кушымтага ярашлы рәвештә документларны соратып ала;

мөрәҗәгать итүченең проект декларациясендә булган мәгълүматларның 214-ФЗ номерлы Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирү фактын билгели;

мөрәҗәгать итүченең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$ статьясында каралган таләпләргә җавап бирмәү фактын ачыклый;

ярашлылык турында бәяләмә проекты яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат проекты әзерли.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.4 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач унике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ гамәлне башкару нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: документларны тикшерү һәм ярашлылык турында бәяләмә яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат проекты әзерли (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта).

3.3.5.2. Бүлек белгече Бүлек башлыгы, башлыкның беренче урынбасары тарафыннан килештерелгән ярашлылык турында бәяләмә проектын яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында хат проектын кул кую өчен Инспекция башлыгына юллый.

Ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмәне бирүдән баш тарту Инспекция башлыгы тарафыннан имзалана, Инспекциянең мөһере белән раслана һәм Бүлектә ярашлылык турында бирелгән бәяләмәләр яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тартулар журналында теркәлә.

Ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту Бүлек белгече тарафыннан торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.5.1 пунктында күрсәтелгән процедуралар тәмамлангач өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе:

Имза салынган, теркәлгән һәм торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган ярашлылык турында бәяләмә яки ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту.

## 3.4. Техник хаталарны (язу, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү

3.4.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документта техник хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Инспекциягә түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шушы Регламентның 3 нче кушымтасына туры китерелгән рәвештә техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү турында гариза;

б) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хаталары (язу, басма хаталары, грамматик яки арифметик хаталары) булган документ;

в) техник хаталар (язу, басма хаталары, грамматик яки арифметик хаталар) булуы турында таныклый торган, юридик көчкә ия булган документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә киткән техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турындагы гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырыла яки почта аша хат итеп җибәрелә.

3.4.2. Документлар белән тәэмин итү һәм тикшереп тору бүлеге белгече техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турындагы гаризаны кабул итә, гаризаны теркәлгән документлары белән бергә теркәүгә ала һәм аларны Бүлек белгеченә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кигән вакыттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.

3.4.3. Бүлек белгече:

документларны карый;

техник хаталары булмаган очракта техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турында карар проекты әзерли, аны килештерү өчен Бүлек башлыгына, башлыкның беренче урынбасарына, соңыннан кул кую өчен Инспекция башлыгына җибәрә. Инспекция башлыгы тарафыннан имзаланган һәм теркәлгән техник хаталарны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турында карарны Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә шәхсән тапшыра яисә гаризада күрсәтелгән адрес буенча почта (электрон почта ярдәмендә) аша җибәрә;

дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документларга төзәтмәләр кертү максатларында ярашлылык турында бәяләмә проектын яисә мондый бәяләмәне бирүдән баш тарту турында хат проектын әзерли, шушы Регламентның 3.4.5.2 пунктында каралган гамәлләрне башкара һәм мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиленә), техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яисә арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен алып калып, кул куйдырып яңартып рәсмиләштерелгән документны тапшыра яисә гаризада күрсәтелгән адрес буенча, Бүлеккә техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яисә арифметик хатасы) булган документның төп нөсхәсен тапшырып, документ алу мөмкинлеге турында почта аша (электрон почта ярдәмендә) хат җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура техник хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата) ачыкланганнан соң яки теләсә нинди кызыксынган заттан җибәрелгән техник хатасы (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хатасы) җибәрелүе хакында гариза алынганнан соңгы өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән)

документ.

3.4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән, орган һәм (яки) вазыйфаи зат гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтү өчен җибәрелгән документка үзгәрешләр керткән очракта, мөрәҗәгать итүчедән түләү алынмый.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эш башкаруның алып барылышы, шул исәптән документларны кабул итү вакытларының һәм тәртибенең үтәлеше;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытлары, тәртибе үтәлүе.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.2. Хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлүен агымдагы контрольлектә тоту Бүлек башлыгы һәм Инспекция башлыгының беренче урынбасары тарафыннан тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольекне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге Инспекциянең структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә, вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне тикшереп тору Инспекция башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Инспекция эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, шулай ук андагы вазыйфаи затларның, дәүләт граждан хезмәткәрләренең карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмауларын) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылу тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүче судка кадәр тәртиптә түбәндәгеләрнең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү хокукына ия:

дәүләт хезмәткәрләренең (вазыйфаи затларның) – Инспекция башлыгына;

Инспекция башлыгының – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Инспекциянең, аның вазыйфаи затының дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре җибәргән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында, КФҮ аша кабул ителергә мөмкин, почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Инспекциянең рәсми сайтыннан (http://gsn.tatarstan.ru), Татарстан

Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан файдаланып җибәрелә ала.

5.4. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуын яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуын шикаять кылганда яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Инспекция тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу

үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта әлеге Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңламтамалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Форма Россия Төзелеш министрлыгының № 653/пр боерыгы белән расланган

**Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә**

№_____________ «___» ____________ 20___ ел.

Төзүче оешманың атамасы:

_______________________________________________________________

Төзүче оешманың төп дәүләт теркәве номеры:

_______________________________________________________________

Төзүче оешманың шәхси тәнгәллек номеры:

_______________________________________________________________

Төзелеш проектының исеме:

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

Капиталь төзелеш объектының адресы:[1]

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

Төзелешкә рөхсәт № _________ бирелү датасы ____________________
бирелгән

________________________________________________________________________

(Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы исеме яки

________________________________________________________________________

төзелешкә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы)

Өлешле төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүнең планлаштырыла торган ысулы:

________________________________________________________________________

(өлешле төзүдә катнашушартнамәсе/ өлешле төзүдә катнашу шартнамәсе, акчаны эскроу сетларында урнаштырып)

Әлеге бәяләмә төзүче оешманың

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе нигезендә күпфатирлы йорт(лар) һәм (яки) блоклап төзелә торган, өч һәм аннан күбрәк блоктан торучы йортлар төзү (булдыру) өчен өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итүгә хокуклы булуын, шулай ук төзүче оешманың һәм төзелеш проекты турындагы проект декларациясенең (20__ елның «_»________ редакциядә) ярашлы булуы турында раслый

________________________________________________________________________

(төзелеш проектының исеме)

«Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларында билгеләнгән таләпләргә туры килә.

Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында белешмәләр кушымтада китерелде.

Бәяләмә бирүгә вәкаләтле вазыйфаи зат

____________________________________________

(вазыйфа атылышы)

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), имза)

[1] Әлеге объект төзелешенә рөхсәт нигезендә капиталь төзелеш объектының адресы күрсәтелә.

Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмәгә кушымта
«___» __________ 20__ ел. № _______

**Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында белешмәләр, өлешле төзелештә катнашучыларның акчалары эскроу счетларында урнаштырылган очракта**

| Ярашлылык турында таләп | | Ярашлылык турында билге[1] |
|---|---|---|
| 1 | Төзүче оешмага карата юридик затны ликвидацияләү процедуралары уздырылмый | |
| 2 | Төзүче оешмага карата арбитраж судының банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларның берсен кертү турында карары юк | |
| 3 | Төзүче оешмага карата административ җәза чарасы сыйфатында аның эшчәнлеген туктату турында арбитраж суды карары юк | |
| 4 | Төзүче оешмага карата предметы капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору һәм мондый капиталь ремонтлау яки төзү, үзгәртеп кору һәм капиталь ремонт эшләрен оештыру йә юридик заттан торак урыннарын сатып алу өлкәсендә эшләр башкарудан, хезмәтләр күрсәтүдән гыйбарәт булган контрактларда яки шартнамәләрдә каралган йөкләмәләрнең аның тарафыннан үтәлүе өлешендә намуссыз тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрларында [2] төзүче оешма (шул исәптән төзүче оешманың бер кулдагы башкарма | |

| | | |
|---|---|---|
| | органы вазыйфаларын башкаручы зат) турында мәгълүматлар юк | |
| 5 | Төзүче оешмага (шул исәптән төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы вазыйфасын башкаручы затка) карата дәүләт мөлкәтендә яки муниципаль мөлкәттә торган җир кишәрлеген сату буенча аукционда, йә дәүләт мөлкәтендә яки муниципаль мөлкәттә торган җир кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукы буенча аукционда намуссыз катнашучылар реестрында мәгълүмат юк[3] | |
| 6 | Төзүче оешманың бер кулдагы башкарма орган функцияләрен гамәлгә ашыручы зат, төзүче оешманың коллегиаль, башкарма органы әгъзасы булып торган зат яисә идарәче компаниянең бер кулдагы башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашыручы зат, әгәр ул төзүче оешманың бер кулдагы башкарма органы функцияләрен гамәлгә ашырса, яисә төзүче оешманың бер кулдагы вакытлыча башкарма органы, ахыр чиктә турыдан-туры яисә читләтеп (өченче затлар аркылы) корпоратив юридик зат-төзүче оешмага хуҗа булган (капиталында 5 проценттан артык күләмдә катнашу өстенлегенә ия булган) физик зат, төзүче оешманың баш бухгалтеры «Күпфатирлы йортларны һәм Күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында « 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3.2 статьясында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә | |
| 7 | Проект декларациясен җибәрү датасына төзүче оешма һәм (яки) аның төп җәмгыяте яки бүлендек җәмгыяте тарафыннан төзелеше өлешле төзелештә катнашу турында төзүче оешма белән мондый күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүдә катнашучыларның беренчесе белән өч һәм аннан күбрәк айга төзелгән шартнамәне дәүләт теркәвенә алу өчен тапшырылган проект декларациясендә күрсәтелгән өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган күпфатирлы йортны һәм (яки) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын файдалануга тапшыру срогын бозу факты ачыкланмады | |
| 8 | Төзүче оешма турында проект декларациясендә күрсәтелгән мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә, [4] | |

| | | |
|---|---|---|
| 9 | Проект декларациясендә күрсәтелгән төзелеш проекты турында мәгълүмат Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килә[4] | |

Бәяләмә бирүгә вәкаләтле вазыйфаи зат

_______________________________________________
(вазыйфа атылышы)

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), имза)

1 Графа «туры килә» форматында тутырыла.

2. Реестрларны алып бару «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

3 Реестрны алып бару Россия Федерациясе Җир кодексының 39.12 статьясындагы 28 һәм 29 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4 «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән.

Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы

йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

**Төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту**

№_____________ «___» ____________ 20___ ел.

Төзүче оешманың атамасы:
______________________________________________________________
Төзүче оешманың төп дәүләт теркәве номеры:
______________________________________________________________
Төзүче оешманың шәхси тәңгәллек номеры:
______________________________________________________________
Төзелеш проектының исеме:
______________________________________________________________
______________________________________________________________
Капиталь төзелеш объектының адресы:[1]
______________________________________________________________
______________________________________________________________
Төзелешкә рөхсәт № _________ бирелү датасы ____________________
бирелгән
______________________________________________________________
(Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы исеме яки
______________________________________________________________

төзелешкә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы)

Өлешле төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итүнең планлаштырыла торган ысулы:

______________________________________________________________________

(өлешле төзүдә катнашушартнамәсе/ өлешле төзүдә катнашу шартнамәсе, акчаны эскроу сетларында урнаштырып)

Төзүче оешма һәм (яки) төзелеш проекты турында (20____ елның «___»_________ редакциядә) проект декларациясе «Күпфатирлы йортларны һәм Күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында « 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларында билгеләнгән түбәндәге таләпләргә туры килми:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

төзүче оешманың № 214-ФЗ Федераль законның 3 статьясының 1.1 һәм 2 өлешләрендә билгеләнгән таләпләргә һәм (яисә) проект декларациясенең № 214-ФЗ Федераль законның 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәвенең ачыкланган фактлары күрсәтелә)

1 кирәкле варианты калдырыла: төзүче һәм проект декларациясе, яисә төзүче, яисә проект декларациясе

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясының 2.2 өлеше нигезендә Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе буенча ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

*Әлеге баш тарту төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә алу максатында Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә яңадан проект декларациясен тапшыруга каршылык була алмый.*

Бәяләмә бирүгә вәкаләтле вазыйфаи зат

_______________________________________

(вазыйфа атылышы)

____________________________________________ ____________________
(Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), имза)

Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы

йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

ТР ДТК инспекциясе башлыгы

________________________________

Кемнән:

____________________________

**Техник хаталарны (язу, басма хаталарын, грамматик яки арифметик хаталарны) төзәтү турында гариза**

Дәүләт хезмәте күрсәтүдә җибәрелгән хаталар турында хәбәр итәм ____________________________________________________________________

(хезмәтнең аталышы)

Язылган:__________________________________________________________

____________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:____________________________________________________

____________________________________________________________________

Техник хаталарны төзәтүне һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1. ______________________________________________________________
2. ______________________________________________________________
3. ______________________________________________________________

Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта мондый карарны:

электрон документны e-mail адресына җибәрү юлы белән:
_________________________________________________________________;

_______________________________________________________________адресы буенча кәгазьдәге документның таныкланган күчермәсе рәвешендә почта аша җибәрүне сорыйм.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда, алар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, тәгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, ябуга, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә) үземнең ризалыгымны (мәнфәгатьләр вәкил аша белдерелгәндә, минем вәкилемнең ризалыгын) раслыйм.

Хәзергесе белән шунысын раслыйм: гаризага кертелгән, минем шәхесемә (мәнфәгатьләр вәкил тарафыннан белдерелгәндә, минем тарафтан вәкил булган затка) кагыла торган, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән белешмәләр дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм дөрес мәгълүматларны үз эченә ала.

_______________ ___________________ ( __________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.)

Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең

бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясының 1[1] һәм 2 өлешләрендә, 3[2], 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе

| Җаваплы затның ФИА | Вазыйфасы | Телефон | Электрон почта адресы |
|---|---|---|---|
| Кудряшов Василий Александрович | Инспекция башлыгы | (843) 237-91-87 | Vasiliy.Kudryashov@tatar.ru |
| Сафиуллин Ильфарт Фәтхрислам улы | Инспекция башлыгының беренче урынбасары | (843) 237-91-87 | Ilfart.Safiullin@tatar.ru |
| Ризванов Фәнзил Рәниф улы | Бүлек башлыгы | (843) 518-36-92 | Fanzil.Rizvanov@tatar.ru |
| Камаев Динар Камил улы | Әйдәп баручы консультант | (843) 518-36-92 | Kamaev.Dinar@tatar.ru |
| Солтанова Динә Илдус кызы | 1 разрядлы өлкән белгеч | (843) 518-36-92 | Dina.Sultanova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь | (843) 264- | Ildar.Sibgatullin@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| һәм юл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе | 77-16 | |
| Юллар һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгы | (843) 264-77-24 | Yuriy.Azin@tatar.ru |